**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№ 3 24.09.2024 ел

**«Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының Урмандеево авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Аксубай муниципаль районының "Урмандеево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар кылды

1.03.10.2024 елда 15 сәгать 00 минутка Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, юлларны кышкы карап тоту шартнамә буенча эшләр өчен түләү )

2) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

- традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (материаллар сатып алу)өчен ремонт , койма кору

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыеннарны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны Урмандеево авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандеево авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев